Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Колшәрип авылы башкарма комитеты

# КАРАРЫ

«20» август 2021 ел №6

Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авылы башкарма комитетының 2018 елның “19” февралендәге 7 номерлы «2018- 2035 елларга Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең социаль инфраструктурысын комплекслы үстерү Программасын раслау турында»гы карарын үз көчен югалткан дип тану турында

Әлмәт шәһәр прокуратурасы бәяләмәсенә һәм программаны гамәлгә ашыруга финанслау чыганаклары булмау турында Әлмәт муниципаль районының контроль-хисап палатасы бәяләмәсенә, шулай ук Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының норматив хокукый актларны законнарга туры китерү турындагы телдән бирелгән күрсәтмәсенә нигезләнеп ,

Колшәрип авылы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авылы башкарма комитетының 2018 елның 19 февралендәге 7 номерлы «2018- 2035 елларга Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең социаль инфраструктурысын комплекслы үстерү Программасын раслау турында» гы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Колшәрип авылы, Тукай урамы, 50 йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет»челтәрендә урнаштырырга

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Колшәрип авылы
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф. Кәшәфетдинов